**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Родники торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2023 елның 10 октябреннән № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Родники авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Родники авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан,тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- юлларны төзекләндерү, ремонтлау һәм карап тоту.
- урамнарны яктыртуны карап тору (лампаларны алыштыру);
- «Ивашан Лисьма» чишмәсенә чыгу күперен төзекләндерү, ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Родники авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен,Родники авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге башлыгы Е.А. Яковлева